ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 июнь 2018 ел № 3214

Башкарма комитетның 2013 елның 11 июнендәге 3490 нчы карары белән расланган ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 11 июнендәге 3490 нчы карары белән (Башкарма комитетның 2013 елның 9 сентябрендәге 5446 нчы, 2016 елның 10 июнендәге 2907 нче карарлары редакциясендә) расланган ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары (алга таба – 2363 нче карар);»;

2) 2.1 пунктның өченче баганасындагы «2393» цифрларын «2363» цифрларына алмаштырырга;

3) 2.3 пунктның икенче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт (5 нче кушымта).

Рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайту.

Кабат рәсмиләштерелгән рөхсәт.

Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирүне кире кагу турында хат.»;

4) 2.4, 2.5, 2.6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, әгәр туктату мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату срогы | Гариза бирү көнен кертеп, 12 көн <1> эчендә.<br>Рөхсәтнең срогын озайту, аны кабат рәсмиләштерү 8 көн эчендә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү срогын туктату каралмаган. | 271-ФЗ санлы Федераль законның 6 маддәсе; 285 нче карарның 5 пункты |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1) Рөхсәт алу турында гариза яки рөхсәтне озайту (кабат рәсмиләштерү) турында гариза (1 нче, 2 нче кушымталар);<br>2) Шәхесне таныклаучы документлар;<br>3) Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документлар (гариза бирүче исеменнән вәкил эш иткән очракта);<br>4) Оештыру документларының күчермәләре (оештыру документларының төп нөсхәләре – күчермәләрнең дөреслеге нотариаль расланмаган очракта);<br>5) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында хокук теркәлмәгән очракта, базар оештыру күздә тотылган территория чикләрендә урнашкан күчемсез милек объектларына хокук билгеләүче документларның расланган күчермәләре.<br>Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бланкын, шәхсән мөрәҗәгать итеп, Башкарма комитеттан алырга мөмкин.<br>Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган. Гариза | 271-ФЗ санлы Федераль законның 5 маддәсе нең 1 пункты; 285 нче карарның 3 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | һәм теркәлгән документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазь йөрткечтә түбәндәге ысулларның берсен файдаланып бирелергә (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (ышаныч язуы нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);<br>тапшыру турында белдерү язуы белән заказлы итеп почта аша.<br>Гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан шулай ук көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да бирелергә (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе;<br>әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>1) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем карый алырлык мәгълүматларны үз эченә алган);<br>2) Юридик затның урнашу урыны буенча салым органында юридик затны исәпкә кую турындагы мәгълүматларны үз эченә алган Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә (ЕГРЮЛ).<br>Гариза бирүче тапшырырга тиешле документларны кабул итү ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы, югарыда санап үтелгән документларны гариза бирүчедән таләп итү тыела. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариза бирүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмау, гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. | |

5) 2.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә.<br>Электрон рәвештә ял (бәйрәм) көнендә кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |

6) 2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Муниципаль хезмәттән файдалана алу мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара эшчәнлегенең саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәтне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләре кулланып | Муниципаль хезмәттән файдалану мөмкинлегенең күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләрнең булуы, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итеп алу өчен кирәкле санда бүлмәләрнең булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең мәгълүмат ресурсларында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүматның булуы.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән характерлана:<br>документлар кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә документлар биргәндә чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче | |

| | | |
|---|---|---|
| | муниципаль хезмәткәрләрнең эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр үзара эшчәнлеге күздә тотыла. Үзара эшчәнлек дәвамлылыгы регламентта билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә (алга таба – күпфункцияле үзәк) күрсәтелгәндә консультация бирүне, документларны кабул итү һәм бирүне күпфункцияле үзәк белгече гамәлгә ашыра.<br>Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турындагы мәгълүматны «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге сайтында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, күпфункцияле үзәктә алырга мөмкин. | |

7) 3.4.1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтәләр (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем карый алырлык мәгълүматларны үз эченә алган);»;

8) 3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Мәгълүмат бирүчеләрнең белгечләре ведомствоара электрон үзара эшчәнлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, соралган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында белдерү кәгазе (алга таба – кире кагу турында белдерү кәгазе) җибәрәләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәге срокларда гамәлгә ашырыла:

- Россреестр белгечләре тарафыннан җибәрелә торган документлар (мәгълүматлар) буенча, өч эш көненнән артык түгел;

- башка мәгълүмат бирүчеләр буенча – федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән очракта, документ яки мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән башлап биш эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яисә кире кагу турында белдерү кәгазе (алга таба – ведомствоара запроска җавап).»;

9) 3 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 3.9 пункт белән тулыландырырга:

«3.9. Рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайту, аны кабат рәсмиләштерү.

Рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайтканда, аны кабат рәсмиләштергәндә әлеге Регламентның 3.3-3.6 пунктларында каралган административ процедуралар гамәлгә ашырыла.»;

10) 5 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгечләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе.»;

11) 5.1 пунктта:

- беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр тәртиптә Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәк белгечләре буенча – күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) шикаять бирергә хокуклы.»;

- түбәндәге эчтәлектәге сигезенче һәм тугызынчы абзацлар белән тулыландырырга:

«8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату.»;

12) 5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазь йөрткечтә яки электрон төрдә бирелә.

Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Татарстан

Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.»;

13) 5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгеченең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.»;

14) 5.4 пунктта:

- 1 пунктчаны «муниципаль хезмәткәрнең» сүзләреннән соң «күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) белгеченең» сүзләре белән тулыландырырга;

- 3 пунктчаны «, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгеченең» сүзләре белән тулыландырырга;

- 4 пунктчаны «, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгеченең» сүзләре белән тулыландырырга;

15) 5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокуый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.

Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап, әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмый, язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон рәвештә гариза бирүчегә җибәрелә.

Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, кимчелекләрне бетерү максатында кабул ителергә тиешле чаралар билгеләнә.»;

16) 5 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 5.9 пункт белән тулыландырырга:

«5.9. Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, шулай ук күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгечләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.»;

17) 1 нче кушымтаны 1 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

18) 2 нче кушымтаны 2 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

19) кушымтада (белешмә) «Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы» юлындагы «Radmir.Belyaev@tatar.ru» сүзләрен «Nch.guzel.Gilyazova@tatar.ru» сүзләренә алмаштырырга;

20) 3 нче кушымтада каралганча 5 нче кушымта белән тулыландырырга.

2. Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы Г.В. Гыйлаҗевага әлеге карарны «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 5 июнендәге
3214 нче карарына
1 нче кушымта

Ваклап сату базарын оештыру
хокукына рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты
Җитәкчесенә

Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт алу турында
**ГАРИЗА**

Юридик затның тулы исеме ____________________________________________
Юридик затның кыскартылган исеме ____________________________________
Юридик затның фирма исеме __________________________________________
Гариза бирүче (юридик зат) ___________________________________________
Юридик затның оештыру-хокукый формасы ______________________________
____________________________________________________________________
Юридик адресы ______________________________________________________
Ваклап сату базарын оештыру күздә тотылган территория чикләрендә урнашкан күчемсез милек объектының яки объектларының урнашу урыны ____________________
____________________________________________________________________
Юридик зат төзелү турында язуның дәүләт теркәү номеры
____________________________________________________________________.
Бердәм дәүләт юридик затларның реестрына юридик зат турында мәгълүматлар кертү фактын раслаучы документ мәгълүматлары _____________________________
____________________________________________________________________
Салым түләүченең идентификация номеры ________________________________
____________________________________________________________________
Юридик затны салым органында исәпкә кую турындагы документ мәгълүматлары
____________________________________________________________________
Оештыру күздә тотыла торган базарның тибы ______________________________

Гаризага түбәндәге сканерланган документлар теркәлә:

1) Шәхесне таныклаучы документлар;

2) Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (гариза бирүче исеменнән вәкил эш иткән очракта);

3) Оештыру документларының күчермәләре (оештыру документларының төп нөсхәләре – күчермәләрнең дөреслеге нотариаль расланмаган очракта);

4) Бердәм дәүләт күчемсез милекнең реестрында хокук теркәлмәгән очракта, базар оештыру күздә тотылган территория чикләрендә урнашкан күчемсез милек объектларына хокук билгеләүче документларның расланган рүчермәләре.

Сораган вакытта сканерланган документларның төп нөсхәләрен бирергә йөкләмә алам.

Гариза бирүче (ФИАи, вазыйфа, тел.) ________________________________
Имза ____________________
М.У.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2018 елның 5 июнендәге
3214 нче карарына
2 нче кушымта

Ваклап сату базарын оештыру
хокукына рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты
Җитәкчесенә

Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәтне озайту (кабат рәсмиләштерү) турында
ГАРИЗА
(кирәклесенең астына сызарга)

Юридик затның тулы исеме ______________________________________________
Юридик затның кыскартылган исеме ______________________________________
Юридик затның фирма исеме ____________________________________________
Гариза бирүче (юридик зат) ____________________________________________
Юридик затның оештыру-хокукый формасы __________________________________
______________________________________________________________________
Юридик адресы _________________________________________________________
Ваклап сату базарын оештыру күздә тотылган территория чикләрендә урнашкан күчемсез милек объектының яки объектларының урнашу урыны ____________________________
______________________________________________________________________
Юридик зат төзелү турында язуның дәүләт теркәү номеры
______________________________________________________________________.
Бердәм дәүләт юридик затларның реестрына юридик зат турында мәгълүматлар кертү фактын раслаучы документ мәгълүматлары _____________________________________
______________________________________________________________________
Салым түләүченең идентификация номеры __________________________________
______________________________________________________________________
Юридик затны салым органында исәпкә кую турындагы документ мәгълүматлары
______________________________________________________________________
Оештыру күздә тотыла торган базарның тибы ________________________________

Гаризага түбәндәге сканерланган документлар теркәлә:

1) Шәхесне таныклаучы документлар;

2) Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (гариза бирүче исеменнән вәкил эш иткән очракта);

3) Оештыру документларының күчермәләре (оештыру документларының төп нөсхәләре – күчермәләрнең дөреслеге нотариаль расланмаган очракта);

4) Бердәм дәүләт күчемсез милекнең реестрында хокук теркәлмәгән очракта, базар оештыру күздә тотылган территория чикләрендә урнашкан күчемсез милек объектларына хокук билгеләүче документларның расланган рүчермәләре.

Сораган вакытта сканерланган документларның төп нөсхәләрен бирергә йөкләмә алам.

Гариза бирүче (ФИАи, вазыйфа, тел.) ______________________________

Имза ____________________

М.У.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2018 елның 5 июнендәге
3214 нче карарына
3 нче кушымта

Ваклап сату базарын оештыру
хокукына рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
5 нче кушымта

Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт

Рөхсәттә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) рөхсәтне биргән җирле үзидарә органының исеме;

2) юридик затның тулы һәм (булган очракта) кыскартылган исеме, шул исәптән фирма исеме һәм оештыру-хокукый формасы, аның урнашу урыны, базар оештыруны күздә тоткан күчемсез милек объектының яки объектларының урнашу урыны;

3) базар тибы;

4) рөхсәтнең гамәлдә булу срогы;

5) салым түләүченең идентификация номеры;

6) рөхсәтнең номеры;

7) рөхсәт бирү турында карар кабул итү датасы.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова